ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**Приказ** **Боерык**

27.09.2022 Казан № 348-од

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 30 мартындагы 79-од номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

**Боерам:**

1. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 30 мартындагы 79-од номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәгә, 3.4.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3.4.2. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгатьне яисә әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының бишенче абзацында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамәне карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән бәяләмә әзерләгәндә, Комитетның дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторының вазыйфаи заты, ришвәтчел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат мөрәҗәгать яки хәбәрнамә

тапшырган дәүләт хезмәткәре белән әңгәмә үткәрергә, аннан язмача аңлатмалар алырга хокуклы, ә Комитет рәисе яки Комитет рәисенең махсус шуңа вәкаләтле урынбасары билгеләнгән тәртиптә дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынган оешмаларга гаризалар җибәрә, «Посейдон» ришвәтчелеккә каршы тору өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасын, шул исәптән соратулар җибәрү өчен дә куллана ала. Мөрәҗәгать яки хәбәрнамә, шулай ук бәяләмә яки башка материаллар, мөрәҗәгать яки хәбәрнамә алынганнан соң, җиде эш көне эчендә Комиссия рәисенә тапшырыла. Гаризалар җибәрелгән очракта, мөрәҗәгать яки хәбәрнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар, мөрәҗәгать яки хәбәрнамә алынганнан соң, 45 көн эчендә Комиссия рәисенә тапшырыла. Билгеләнгән вакыт озайтылырга мөмкин, ләкин 30 көннән артык түгел.».

2. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторы мөдиренә (О.А. Филипповага):

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә җибәрүне тәэмин итәргә;

әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының дәүләт граждан хезмәткәрләре игътибарына җиткерергә;

әлеге боерыкны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары Ю.Б. Матвеевка йөкләргә.

Рәис Ф.С. Батков